**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

2022 ел, 15 август №15

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында 2022-2026 елларга кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 28.06.2022 N 197-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Дәвеш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегендә 2022-2026 елларга кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган 20222-2026 елларга Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 бүлекнең дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече яисә урта эшкуарлыкның һәр субъектына шундый мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карар турында, ул кабул ителгәннән соң биш көн эчендә хәбәр ителергә тиеш.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Дәвеш авыл
җирлеге Башлыгы Т.Т. Хөсәенов